**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменения в Административный регламент предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений»**

1. Внести в Административный регламент предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений», утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 27 декабря 2022 года № УП-930 «Об утверждении Административного регламента предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений» (с изменениями, внесенными указами Раиса Республики Татарстан от 12 апреля 2023 года № 231 и от 23 ноября 2023 года № 799), изменение, изложив его в новой редакции согласно приложению.

2. Настоящий Указ вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
18 июля 2026 года
№ 577

Приложение
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «18» июля 2026 года

№ 577

# АДМИНИСТРАТИВНЫЙ РЕГЛАМЕНТ
## предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений»

### I. Общие положения

1.1. Настоящий Административный регламент устанавливает порядок и стандарт предоставления государственной услуги «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений».

1.2. Государственная услуга (перечень условных обозначений и сокращений приведен в приложении к настоящему Административному регламенту) предоставляется гражданам, индивидуальным предпринимателям и юридическим лицам. Заявитель может воспользоваться государственной услугой лично либо через своего уполномоченного представителя.

1.3. Государственная услуга предоставляется заявителю в соответствии с категориями (признаками) заявителей, сведения о которых размещаются в федеральной государственной информационной системе «Федеральный реестр государственных и муниципальных услуг (функций)», на Едином портале и Республиканском портале (при наличии технической возможности).

Идентификаторы категорий (признаков) заявителей приведены в приложении к настоящему Административному регламенту.

### II. Стандарт предоставления государственной услуги

#### 2.1. Наименование государственной услуги

2.1.1. Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений.

2.2. Наименование органа, предоставляющего государственную услугу

2.2.1. Государственную услугу предоставляет Министерство лесного хозяйства Республики Татарстан.

2.3. Результат предоставления государственной услуги

2.3.1. Результатом предоставления государственной услуги является решение о согласовании проекта лесоразведения и внесения в него изменений.

Формирование реестровой записи в качестве результата предоставления государственной услуги не предусмотрено.

2.3.2. Результат предоставления государственной услуги направляется заявителю в форме электронного документа, подписанного усиленной квалифицированной электронной подписью уполномоченного должностного лица Министерства в соответствии с Федеральным законом от 6 апреля 2011 года № 63-ФЗ «Об электронной подписи», в личный кабинет заявителя в ФГИС ЛК, на Едином портале или Республиканском портале (при наличии технической возможности) в зависимости от способа подачи запроса.

2.4. Срок предоставления государственной услуги

2.4.1. Максимальный срок предоставления государственной услуги, независимо от категории (признаков) заявителя и способа подачи запроса, составляет не более пяти рабочих дней со дня регистрации запроса, документов и (или) информации, необходимых для предоставления государственной услуги.

2.5. Размер платы, взимаемой с заявителя при предоставлении государственной услуги, и способы ее взимания

2.5.1. Взимание государственной пошлины или иной платы за предоставление государственной услуги законодательством Российской Федерации не предусмотрено.

2.6. Срок регистрации запроса заявителя о предоставлении государственной услуги

2.6.1. Запрос, документы и (или) информация, необходимые для предоставления государственной услуги, поданные через ФГИС ЛК, регистрируются в автоматическом режиме в день их подачи. В личном кабинете заявителя отображается уведомление об изменении статуса запроса, подтверждающее, что запрос отправлен, с указанием регистрационного номера и даты подачи запроса.

2.6.2. Запрос, документы и (или) информация, необходимые для предоставления государственной услуги, поданные на Едином портале или Республиканском портале (при наличии технической возможности) до 18:00 рабочего дня, регистрируются в Министерстве в день их подачи, поданные после 18:00 рабочего дня либо в выходной или нерабочий праздничный день – на следующий рабочий день.

2.7. Показатели доступности и качества государственной услуги

2.7.1. Перечень показателей доступности и качества государственной услуги размещается на официальном сайте Министерства, а также на Едином портале или Республиканском портале (при наличии технической возможности).

2.7.2. Заявителям обеспечивается возможность оценить доступность и качество государственной услуги на официальном сайте Министерства, а также на Едином портале или Республиканском портале (при наличии технической возможности).

2.8. Иные требования к предоставлению государственной услуги

2.8.1. Иные услуги, которые являются необходимыми и обязательными для предоставления государственной услуги, законодательством Российской Федерации не предусмотрены.

2.8.2. Перечень информационных систем, используемых для предоставления государственной услуги:

а) ФГИС ЛК;

б) Единый портал;

в) Республиканский портал (при наличии технической возможности);

г) ЕСИА;

д) СМЭВ.

2.8.3. Информация о порядке предоставления государственной услуги размещается на государственных языках Республики Татарстан на официальном сайте Министерства.

2.8.4. Невозможность предоставления законному представителю несовершеннолетнего, не являющемуся заявителем, результатов предоставления государственной услуги в отношении несовершеннолетнего, оформленных в форме документа на бумажном носителе в случае, если заявитель в момент подачи запроса выразил письменно желание получить запрашиваемые результаты предоставления государственной услуги в отношении несовершеннолетнего лично, обусловлена предоставлением государственной услуги только совершеннолетним лицам и исключительно в электронной форме.

2.8.5. Порядок предоставления результатов государственной услуги в отношении несовершеннолетнего, оформленных в форме документа

на бумажном носителе, в том числе способы и сроки их предоставления законному представителю несовершеннолетнего, не являющемуся заявителем, не определен в связи с предоставлением государственной услуги только совершеннолетним лицам и исключительно в электронной форме.

2.8.6. Предоставление государственной услуги в государственном бюджетном учреждении «Многофункциональный центр предоставления государственных и муниципальных услуг в Республике Татарстан» не предусмотрено.

## 2.9. Исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги

2.9.1. Исчерпывающий перечень документов, необходимых в соответствии с законодательными и иными нормативными правовыми актами для предоставления государственной услуги, приведен в приложении к настоящему Административному регламенту с разделением на документы и информацию, которые заявитель представляет самостоятельно, и документы, которые заявитель вправе представить по собственной инициативе, так как они подлежат представлению в рамках межведомственного информационного взаимодействия.

2.9.2. Сведения о формах запроса и документов, необходимых для предоставления государственной услуги, приведены в приложении к настоящему Административному регламенту.

## 2.10. Исчерпывающий перечень оснований для отказа в приеме запроса о предоставлении государственной услуги и документов, необходимых для предоставления государственной услуги, и исчерпывающий перечень оснований для приостановления предоставления государственной услуги или для отказа в предоставлении государственной услуги

2.10.1. Основания для отказа в приеме запроса и документов, необходимых для предоставления государственной услуги, отсутствуют.

2.10.2. Основания для приостановления предоставления государственной услуги отсутствуют.

2.10.3. Основаниями для отказа в предоставлении государственной услуги являются:

а) представление недостоверных, неполных либо не соответствующих требованиям, установленным настоящим Административным регламентом, документов;

б) представление электронных образов документов, необходимых для предоставления государственной услуги, не позволяющих в полном объеме прочитать текст указанных документов и (или) их реквизиты;

в) недостоверность сведений, указанных в проекте лесоразведения и внесения в него изменений;

г) несоответствие сведений, указанных в проекте лесоразведения и внесения в него изменений, требованиям, предусмотренным приказом Минприроды России от 20 декабря 2021 года № 978;

д) несоответствие проекта лесоразведения и внесения в него изменений форме проекта лесоразведения, предусмотренной приказом Минприроды России от 20 декабря 2021 года № 978.

2.10.4. Исчерпывающий перечень оснований для отказа в предоставлении государственной услуги с учетом категории (признаков) заявителя приведен в приложении к настоящему Административному регламенту.

2.10.5. В случае отказа в предоставлении государственной услуги Министерство информирует заявителя о причинах такого отказа с указанием перечня документов и информации, отсутствие и (или) недостоверность которых стали причиной отказа, а также с указанием перечня установленных федеральными законами и (или) иными нормативными правовыми актами требований, несоответствие которым повлекло отказ в предоставлении государственной услуги.

## III. Состав, последовательность и сроки выполнения административных процедур

### 3.1. Перечень осуществляемых при предоставлении государственной услуги административных процедур

3.1.1. Предоставление государственной услуги включает в себя следующие административные процедуры:

а) профилирование заявителя;

б) прием запроса, документов и (или) информации, необходимых для предоставления государственной услуги;

в) межведомственное информационное взаимодействие;

г) принятие решения о предоставлении (об отказе в предоставлении) государственной услуги;

д) предоставление результата государственной услуги.

## IV. Способы информирования заявителя об изменении статуса рассмотрения запроса о предоставлении государственной услуги

4.1. Информирование заявителя об изменении статуса рассмотрения запроса осуществляется в автоматическом режиме в личном кабинете заявителя в ФГИС ЛК, на Едином портале или Республиканском портале (при наличии технической возможности).

Приложение
к Административному регламенту
предоставления Министерством
лесного хозяйства Республики
Татарстан государственной услуги
«Согласование проекта
лесоразведения и внесения в него
изменений»

**Перечень условных обозначений и сокращений, идентификаторы категорий (признаков) заявителей, исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги, исчерпывающий перечень оснований для отказа в приеме запроса и документов, необходимых для предоставления государственной услуги, оснований для приостановления предоставления государственной услуги или отказа в предоставлении государственной услуги, сведения о формах запроса о предоставлении государственной услуги и документов, необходимых для предоставления государственной услуги**

## I. Перечень условных обозначений и сокращений

1. Сокращения:

а) государственная услуга – государственная услуга «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений»;

б) заявитель – гражданин, индивидуальный предприниматель, юридическое лицо, обратившиеся с запросом о предоставлении государственной услуги;

в) Министерство – Министерство лесного хозяйства Республики Татарстан;

г) запрос – запрос о предоставлении государственной услуги «Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений»;

д) Единый портал – федеральная государственная информационная система «Единый портал государственных и муниципальных услуг (функций)» (https://www.gosuslugi.ru);

е) Республиканский портал – государственная информационная система Республики Татарстан «Портал государственных и муниципальных услуг Республики Татарстан» (https://uslugi.tatarstan.ru);

ж) ФГИС ЛК – федеральная государственная информационная система лесного комплекса (https://pub.fgislk.gov.ru);

з) ЕСИА – федеральная государственная информационная система «Единая система идентификации и аутентификации в инфраструктуре,

обеспечивающей информационно-технологическое взаимодействие информационных систем, используемых для предоставления государственных и муниципальных услуг в электронной форме» (https://esia.gosuslugi.ru);

и) СМЭВ – информационная система межведомственного электронного взаимодействия;

к) приказ Минприроды России от 20 декабря 2021 года № 978 – приказ Министерства природных ресурсов и экологии Российской Федерации от 20 декабря 2021 года № 978 «Об утверждении Правил лесоразведения, формы, состава, порядка согласования проекта лесоразведения, оснований для отказа в его согласовании, а также требований к формату в электронной форме проекта лесоразведения»;

л) приказ Минприроды России от 22 августа 2022 года № 542 – приказ Министерства природных ресурсов и экологии Российской Федерации от 22 августа 2022 года № 542 «Об утверждении перечня документов в электронной форме, формирование, предварительная автоматизированная проверка и направление которых возможны с использованием электронного сервиса «личный кабинет», предусмотренного частью 1 статьи 93.5 Лесного кодекса Российской Федерации, а также порядка использования юридическими лицами, гражданами электронного сервиса «личный кабинет».

2. Условные обозначения:

а) ЭД – электронный документ;

б) ЭОД – электронный образ документа;

в) ЕПГУ – Единый портал;

г) РПГУ – Республиканский портал (при наличии технической возможности).

## II. Идентификаторы категорий (признаков) заявителей

| № п/п | Результат предоставления государственной услуги | Отдельные категории (признаки) заявителей | Идентификатор отдельного признака заявителя |
|---|---|---|---|
| 1 | Согласование проекта лесоразведения и внесения в него изменений | Гражданин, обратившийся лично | А |
| 2 | | Индивидуальный предприниматель, обратившийся лично | Б |
| 3 | | Лицо, имеющее право без доверенности действовать от имени юридического лица | В |
| 4 | | Представитель заявителя, действующий по доверенности | Г |

## III. Исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги

| № п/п | Идентификатор категорий (признаков) заявителей | Перечень документов и информации, необходимых для предоставления государственной услуги | Способы подачи документов, требования к представлению документов |
|---|---|---|---|
| 1 | Исчерпывающий перечень документов и информации, необходимых для предоставления государственной услуги, которые заявитель должен представить самостоятельно | | |
| 1.1 | А – Г | Запрос | ЭД через ФГИС ЛК, ЕПГУ или РПГУ |
| 1.2 | Г | Документ, подтверждающий полномочия представителя заявителя | ЭОД или ЭД через ФГИС ЛК, ЕПГУ или РПГУ |
| 1.3 | А – Г | Проект лесоразведения и внесения в него изменений | ЭД через ФГИС ЛК, ЕПГУ или РПГУ |
| 2 | Исчерпывающий перечень документов, необходимых для предоставления государственной услуги, которые заявитель вправе представить по собственной инициативе, так как они подлежат представлению в рамках межведомственного информационного взаимодействия | | |
| 2.1 | А – Г | Информация о соответствии данных, представленных заявителем, данным государственного лесного реестра по соответствующему лесному участку | ЭОД или ЭД через ФГИС ЛК, ЕПГУ или РПГУ |
| 2.2 | В, Г | Выписка из Единого государственного реестра юридических лиц | ЭОД или ЭД через ФГИС ЛК, ЕПГУ или РПГУ |
| 2.3 | Б, Г | Выписка из Единого государственного реестра индивидуальных предпринимателей | ЭОД или ЭД через ФГИС ЛК, ЕПГУ или РПГУ |

## IV. Исчерпывающий перечень оснований для отказа в приеме запроса и документов, необходимых для предоставления государственной услуги, оснований для приостановления предоставления государственной услуги или отказа в предоставлении государственной услуги

| № п/п | Идентификатор категорий (признаков) заявителей | Перечень оснований |
|---|---|---|
| 1 | Исчерпывающий перечень оснований для отказа в приеме запроса и документов, необходимых для предоставления государственной услуги | |
| 1.1 | А – Г | Основания для отказа в приеме запроса и документов, необходимых для предоставления государственной услуги, отсутствуют |
| 2 | Исчерпывающий перечень оснований для приостановления предоставления государственной услуги | |
| 2.1 | А – Г | Основания для приостановления предоставления государственной услуги отсутствуют |
| 3 | Исчерпывающий перечень оснований для отказа в предоставлении государственной услуги | |
| 3.1 | А – Г | Представление недостоверных, неполных либо не соответствующих требованиям, установленным настоящим Административным регламентом, документов |
| 3.2 | А – Г | Представление ЭОД, необходимых для предоставления государственной услуги, не позволяющих в полном объеме прочитать текст указанных документов и (или) их реквизиты |
| 3.3 | А – Г | Недостоверность сведений, указанных в проекте лесоразведения и внесения в него изменений |
| 3.4 | А – Г | Несоответствие сведений, указанных в проекте лесоразведения и внесения в него изменений, требованиям, предусмотренным приказом Минприроды России от 20 декабря 2021 года № 978 |
| 3.5 | А – Г | Несоответствие проекта лесоразведения и внесения в него изменений форме проекта лесоразведения, предусмотренной приказом Минприроды России от 20 декабря 2021 года № 978 |

## V. Сведения о формах запроса о предоставлении государственной услуги и документов, необходимых для предоставления государственной услуги

1. Электронная форма запроса формируется автоматически в соответствии с приказом Минприроды России от 22 августа 2022 года № 542 в личном кабинете заявителя в ФГИС ЛК, на Едином портале или Республиканском портале (при наличии технической возможности).

2. Форма проекта лесоразведения утверждена приказом Минприроды России от 20 декабря 2021 года № 978.

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2022 елның 27 декабрендәге ПУ-930 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 12 апрелендәге 231 номерлы һәм 2023 елның 23 ноябрендәге 799 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 18 июль
№ 577

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның « 18 » июлендәге
577 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең**
**АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламентта «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм стандарты билгеләнә.

1.2. Дәүләт хезмәте (шартлы билгеләр һәм кыскартылмалар исемлеге әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә) гражданнарга, шәхси эшкуарларга, юридик затларга күрсәтелә. Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән шәхсән яисә үзенең вәкиле аша файдалана ала.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчегә гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында мәгълүмат «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, Бердәм порталда һәм Республика порталында (техник мөмкинлекләр булган очракта) урнаштырыла.

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары әлеге Административ регламентка кушымтада бирелгән.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

2.1.1. Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе

2.3.1. Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү турында карар дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып тора.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак реестр язмасын формалаштыру каралмаган.

2.3.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куйган электрон документ рәвешендә, соратуны нинди ысул белән бирелүгә карап, гариза бирүченең УК ФДМСындагы, Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы (техник мөмкинлекләр булган очракта) шәхси кабинетына юллана.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы гариза бирүченең категориясенә (билгеләренә) һәм соратуны бирү ысулына бәйсез рәвештә соратуны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат теркәлгән көннән биш эш көненнән дә артып китми.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләүнең күләме һәм аны алу ысуллары

2.5.1. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы яисә башка түләүләр алу каралмаган.

## 2.6. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуын теркәү срогы

2.6.1. УК ФДМС аша бирелгән сорату, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат алар бирелгән көнне автомат рәвештә теркәлә. Гариза бирүченең шәхси кабинетында соратуның юллануын раслап, соратуның статусы үзгәрүе турында соратуны теркәү номеры һәм бирелү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә барлыкка килә.

2.6.2. Бердәм портал яисә Республика порталы (техник мөмкинлекләр булган очракта) аша эш көнендә 18:00 гә кадәр бирелгән сорату, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат Министрлыкта бирелгән көнендә теркәлә, эш көнендә 18:00 дән соң яисә ял көнендә яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә бирелгәннәре – икенче эш көнендә теркәлә.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалана алу дәрәҗәсе һәм аның сыйфаты күрсәткечләре

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлекләре һәм аның сыйфаты күрсәткечләре исемлеге Министрлыкның рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлекләр булган очракта) урнаштырыла.

2.7.2. Гариза бирүчеләргә Министрлыкның рәсми сайтында, шулай ук Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлекләр булган очракта) дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлекләрен һәм аның сыйфатын бәяләү мөмкинлеге бирелә.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр

2.8.1. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка хезмәтләр каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган мәгълүмат системалары исемлеге:

а) УК ФДМС;

б) Бердәм портал;

в) Республика порталы (техник мөмкинлекләр булган очракта);

г) ИАБС;

д) ВЭХС.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

2.8.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаган затка карата күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең соратыла торган нәтиҗәләрен шәхсән алу теләген язмача белдергән очракта, балигъ булмаган затның гариза бирүче булып тормаган законлы вәкиленә балигъ булмаган затка карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәсе дәүләт хезмәтенең бары тик балигъ булган затларга һәм бары тик электрон рәвештә генә күрсәтелүе шарты сәбәпле бирелми.

2.8.5. Балигъ булмаган затка карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәсен бирү, шул исәптән аларны балигъ булмаган затның гариза бирүче булмаган законлы вәкиленә бирү ысуллары һәм сроклары, дәүләт хезмәтенең бары тик балигъ булган затларга һәм бары тик электрон рәвештә генә күрсәтелүе шарты сәбәпле билгеләнми.

2.8.6. Дәүләт хезмәтен «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтү каралмаган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.9.1. Законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшыру мәҗбүри булган, гариза бирүче үз инициативасы белән бирергә хокуклы документларга бүленеп, әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә.

2.9.2. Соратуның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның формалары турында мәгълүмат әлеге Административ регламентка кушымтада бирелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.10.1. Соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.10.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

а) дөрес булмаган, тулы булмаган яисә әлеге Административ регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документлар тапшыру;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларның әлеге документларны һәм (яисә) аларның реквизитларын тулысынча уку мөмкинлек бирми торган электрон образларын тапшыру;

в) урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектында күрсәтелгән мәгълүматларның дөрес булмавы;

г) урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектында күрсәтелгән мәгълүматларның Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

д) урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектының Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карарында билгеләнгән урман утырту проекты формасына туры килмәве.

2.10.4. Гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Административ регламентка кушымтада бирелгән.

2.10.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Министрлык гариза бирүчегә аларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып торган документлар һәм мәгълүмат

исемлеген күрсәтеп, шулай ук аларга туры килмәү дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр исемлеген күрсәтеп, гариза бирүчегә хәбәрнамә юллый.

## III. Административ процедураларның составы, башкару эзлеклелеге һәм сроклары

### 3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә башкарыла торган административ процедуралар исемлеге

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ процедуралар башкару күздә тотыла:

а) гариза бирүченең профилен билгеләү;

б) соратуны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

в) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

д) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны карап тикшерү статусына үзгәрешләр кертелү турында гариза бирүчегә мәгълүмат юллау ысуллары

4.1. Гариза бирүчегә соратуны карап тикшерү статусына үзгәрешләр кертелү турында мәгълүмат гариза бирүченең УК ФДМСындагы, Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы (техник мөмкинлекләр булган очракта) шәхси кабинетына автомат рәвештә юлланыла.

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгы
тарафыннан «Урман утырту һәм
аңа үзгәрешләр кертү проектын
килештерү» дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
кушымта

**Шартлы билгеләр һәм кыскартылмалар исемлеге, гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге, соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның формалары турында мәгълүматлар**

I. Шартлы билгеләр һәм кыскартылмалар исемлеге

1. Кыскартылмалар:

а) дәүләт хезмәте – «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәте;

б) гариза бирүче – дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорату белән мөрәҗәгать иткән граждан, шәхси эшкуар һәм юридик зат;

в) Министрлык – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы;

г) сорату – «Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү» дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорату;

д) Бердәм портал – «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://www.gosuslugi.ru);

е) Республика порталы – «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (www.uslugi.tatarstan.ru);

ж) УК ФДМС – урман комплексының федераль дәүләт мәгълүмат системасы (https://pub.fgislk.gov.ru);

з) ИАБС – «Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (https://esia.gosuslugi.ru);

и) ВЭХС – ведомствоара электрон хезмәттәшлек мәгълүмат системасы;

к) Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карары – Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман утырту кагыйдәләрен, урман утырту проектын килештерү формасын, составын һәм тәртибен, аны килештерүдән баш тарту өчен нигезләрне, шулай ук урман утырту проектының электрон формадагы форматына карата таләпләрне раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карары;

л) Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 22 августындагы 542 номерлы карары – Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе Урман кодексының 93.5 статьясы 1 кисәгендә каралган «шәхси кабинет» электрон сервисын файдаланып формалаштыру, алдан автоматлаштырылган тикшерү һәм юллау мөмкин булган электрон рәвештәге документлар исемлеген, шулай ук юридик затларның, гражданнарның «шәхси кабинет» электрон сервисыннан файдалану тәртибен раслау турында» 2022 елның 22 августындагы 542 номерлы карары.

2. Шартлы билгеләр:

а) ЭД – электрон документ;

б) ДЭО – документның электрон образы;

в) ДХБП – Бердәм портал;

г) ДХРП – Республика порталы (техник мөмкинлекләр булган очракта).

## II. Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| Т/с | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре (билгеләре) | Гариза бирүченең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектын килештерү | Шәхсән мөрәҗәгать иткән граждан | А |
| 2 | | Шәхсән мөрәҗәгать иткән шәхси эшкуар | Б |
| 3 | | Юридик зат исеменнән ышанычнамәдән башка эш итү хокукына ия зат | В |
| 4 | | Гариза бирүченең ышанычнамә нигезендә эш йөртә торган вәкиле | Г |

III. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| Т/с | Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат исемлеге | Документларны тапшыру ысуллары, документларны тапшыруга карата таләпләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документларның һәм мәгълүматның тулы исемлеге | | |
| 1.1 | А – Г | Сорату | УК ФДМС, ДХБП яисә ДХРП аша ЭД |
| 1.2 | Г | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | УК ФДМС, ДХБП яисә ДХРП аша ДЭО яисә ЭД |
| 1.3 | А – Г | Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проекты | УК ФДМС, ДХБП яисә ДХРП аша ЭД |
| 2 | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшыру мәҗбүри булган, гариза бирүче үз инициативасы белән бирергә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге | | |
| 2.1 | А – Г | Тиешле урман кишәрлеге буенча гариза бирүче тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дәүләт урман реестрындагы мәгълүматларга туры килүе турында мәгълүмат | УК ФДМС, ДХБП яисә ДХРП аша ДЭО яисә ЭД |
| 2.2 | В, Г | Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | УК ФДМС, ДХБП яисә ДХРП аша ДЭО яисә ЭД |
| 2.3 | Б, Г | Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | УК ФДМС, ДХБП яисә ДХРП аша ДЭО яисә ЭД |

## IV. Соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| Т/с | Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторы | Нигезләр исемлеге |
|---|---|---|
| 1 | Соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | |
| 1.1 | А – Г | Соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк |
| 2 | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрнең тулы исемлеге | |
| 2.1 | А – Г | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк |
| 3 | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | |
| 3.1 | А – Г | Дөрес булмаган, тулы булмаган яисә әлеге Административ регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килми торган документлар тапшыру |
| 3.2 | А – Г | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларның әлеге документларны һәм (яисә) аларның реквизитларын тулысынча уку мөмкинлек бирми торган ДЭО тапшыру |
| 3.3 | А – Г | Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектында күрсәтелгән мәгълүматларның дөрес булмавы |
| 3.4 | А – Г | Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектында күрсәтелгән мәгълүматларның Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве |
| 3.5 | А – Г | Урман утырту һәм аңа үзгәрешләр кертү проектының Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карарында билгеләнгән урман утырту проекты формасына туры килмәве |

## V. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның формалары турында мәгълүмат

1. Соратуның электрон формасы Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 22 августындагы 542 номерлы карары нигезендә гариза бирүченең УК ФДМСындагы, Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы (техник мөмкинлекләр булган очракта) шәхси кабинетында автомат рәвештә формалаштырыла.

2. Урман утырту проекты Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 20 декабрендәге 978 номерлы карары нигезендә расланды.

---